**СОВЕТ МЕМДЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422728, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Мемдель, ул.Кооперативная, д.30,

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘМДӘЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422728, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Мәмдәл авылы, Кооператив ур., 30

Тел./факс: +7(84365) 60-2-37 , e-mail: Memdel.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«23» апреля 2018 года** **№ 85**

**Мәмдәл авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 апрелендәге 51 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге территориясендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Мәмдәл авыл җирлегенең норматив-хокукый актларын «Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 29.12.2017 ел, № 455-ФЗ Федераль законга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге Советы

**КАРАР:**

1. Мәмдәл авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 апрелендәге 51 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге территориясендә халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба - текст буенча Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6.2 пунктының 3 пунктчасы. Нигезләмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияләрне планлаштыру проектлары һәм территорияләрне ызанлау проектлары, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очраклардан тыш, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, шулай ук җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләләре, рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп коруның чик параметрларыннан тайпылу мәсьәләләре, җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләләре, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда;».

1.2. Нигезләмәнең 6.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты.».

2. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендә рәсми сайтында урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерелергә тиеш http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Сафиуллин